ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
от 20.09.2017 №18

Референдум уздыру
инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башкарма комитеты

К А Р А Р БИРӘ:»

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:

- Куюк-Ерыкса торак пунктында су алу башнясын алыштыру;

- Куюк-Ерыкса торак пунктында (2 шт.), Яңа Кумазан торак пунктында, Зур Шия торак пунктында, Малмыжка торак пунктында, Гришкино торак пунктында су алу башняларын саклау;

- Зур Шия торак пунктында суүткәргеч челтәрләрен алыштыру (2 км);

- Куюк-Ерыкса торак пунктында (2 шт.), Яңа Кумазан торак пунктында, Зур Шия торак пунктында, Малмыжка торак пунктында, Гришкино торак пунктында су алу башняларына насослар белән идарә итү өчен автоматика сатып алу һәм урнаштыру.

2. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Куюк-Ерыкса торак пунктында (2 шт.), Яңа Кумазан торак пунктында, Зур Шия торак пунктында, Малмыжка торак пунктында, Гришкино торак пунктында янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Р.Шәйхетдинов